Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге

Советы КАРАР № 5

Балыклы-Чүкәй авылы 2024 елның 01 нче августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 21.08.2023 №16 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 21.08.2023 №16 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урамы, 23 А йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башлыгы: И.С.Мазитов